КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 18 ноябрь г.Казань № 1102

«Татарстан Республикасының Дәүләт симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесенә «Академик» исеме бирү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт театрларына һәм концерт оешмаларына «Академик» исеме бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 9 октябрь, 962 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективларын стимуллау, үстерү һәм аларга ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының түбәндәге тәкъдимнәрен кабул итәргә:

«Татарстан Республикасының Дәүләт симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесенә «Академик» исемен бирү турында;

«Татарстан Республикасының Дәүләт симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе исемен «Татарстан Республикасының Дәүләт академик симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе (алга таба – Учреждение) итеп үзгәртү турында.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына 60 көн эчендә Учреждение уставына тиешле үзгәрешләрне кертергә һәм билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин